

БИШЕК ҖЫРЛАРЫ

КАЗАН «МӘГАРИФ» 1993



БИШЕК ЯНЫНДА *

Татар халык җыры

Әлли-бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Бәү-бәү итеп, күз йомып,
Изрәп кенә китәр бу.
Алма кебек тәгәрәп,
Үсеп буйга җитәр бу,
Абыйлары артыннан
Казаннарга китәр бу.

---

* Татар халык көе

Казаннарда укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Әлли-бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның;
Алдына алып йоклатырга
Үз әбкәсе бар аның.

Ал бишеге бар аның,
Гөл бишеге бар аның,
Тәрбияләп үстерергә
Үз әнкәсе бар аның.





Үчтеки-үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки,
Илдә-Җирдә бер булып,
Бер дип әйткән ул булыр.

Минем кызым бик иркә,
Башларында кәсинкә,
Күлмәге дә сәргинкә,





Аягында бәтинкә,
Алтын чәчле, зәңгәр күзле
Коеп куйган кәртинкә.

Үс, үс, улым, үс әйдә,
Дөнья бик киң, сыярсың,
Аягың җиргә терәрсең,
Башың күккә сузарсың.
Бу җирләргә сыймасаң,
Галәмнәргә чыгарсың;
Күчтәнәчләр апкайтып,
Әнкәеңне сыйларсың.

Әлли итәр бу бала,
Бәлли итәр бу бала,
Әткәсенә, әнкәсенә
Хезмәт итәр бу бала.





БӘЛЛҮ *

Дәрдемәнд шигыре

Кыйгач кашым,
Асыл ташым!
  Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
  Бәүкәй, бәллү-бәү!

---

* Бу шигырьгә композиторлар Шамил Шәрифуллин һәм Резеда Ахиярова көй язган.

Хублар хубы,
Алма тубы,
Пешкән, тулгансың,
Бу чагында
Син тагын да
Чибәр булгансың!
Алмакаем,
Аппаккаем,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү-бәү!





Җилбер-җилбер
Син бик тилбер —
Күбрәк уйныйсың!
Ал гөлләрне,
Сөнбелләрне
Өзми куймыйсың.
Кил, гөлкәем,
Сөнбелкәем,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү-бәү!





Йокла шунда...
Син төшеңдә
    Колын менерсең;
Алмачобар,
Арбасы бар —
    Менә күрерсең!
Колынкаем,
Кил, җанкаем,
    Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
    Бәүкәй, бәллү-бәү!





Юл юлдашың
Һәм кулдашың
    Сиңа бар эштә,
Һәм саклаучы,
Һәм яклаучы
    Булсын фәрештә.
Ҡил, бөдрәкәй,
Фәрештәкәй,
    Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
    Бәүкәй, бәллү-бәү!





2 К-11


БИШЕК ҖЫРЫ *

Туфан Миңнуллин шигыре

Куанычларым, шатлыгым булып,
Балам — багалмам, үсәрсеңме син?
Сагынып җырлар җырыма минем,
Күземнең нуры, күчәрсеңме син?

Бәхет гөлемнең чәчәге булып,
Былбыл кошкаем, яшәрсеңме син?
Әнием диеп, кадерлем диеп,
Сандугачкаем, дәшәрсеңме син?

Гомерең сукмагын зур юллар буйлап,
Өмет йолдызым, үтәрсеңме син?
Илеңнең данын намус, вөҗданың,
Балам, әй балам, итәрсеңме син?



* Бу шигырьгә композитор Рәшит Абдуллин көй язган.



БОРЫНГЫ БИШЕК ҖЫРЫ

Әлли-бәлли итәдер,
Бәләкәй матур бәбкәсе;
Еламаса, йокласа,
Рәхмәт укыр әнкәсе.

Гомере булса, зуррак үссә
Сабак укыр бәбкәсе;
Сабагыны матур белсә,
Бик яратыр әткәсе.

Әткәсенең, әнкәсенең
Бер генә шул бәбкәсе.
Бу бәләкәй бәбкәбезне
Күрсә яратыр әбкәсе.

Бәбкәбезне күрергә килми
Ничек түзә әбкәсе?
Килсә килсен бүләк берлән,
Буш килмәсен әбкәсе!





БИШЕК ҖЫРЫ *

Габдулла Тукай шигыре

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, углым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым,
Кичтән йокың кала да,
Еглап үтә көндезең.

* Татар халык көе.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем,
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син,
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!





ҚЫЗЫМА *

Муса Җәлил шигыре

Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем,
Йөрәгемдә кабынган
Шатлык җырым син минем.

---

* Бу шигырьгә Җәүдәт Фәйзи көй язган.

Синең гомрең җыр булып
Яңрар бәхет илендә,
Йолдыз булып янарсың
Син туган ил күгендә.

Таңнан торып, бакчада
Син уйнадың көнозын.
Аргансыңдыр, кил, кызым,
Йокла инде, йолдызым!

Әлли-бәлли, бәлли-бәү!
Әлли-бәлли, бәлли-бәү!





ЙОҚЛА, БАЛАМ *

Әхмәт Ерикәй шигыре

Күктән ай елмая, йолдызлар яна,
Матур елгаларда сикереп су ага.
Син тауларда йөрдең, диңгездә гиздең,
Парашютчы булдың — күктән сикердең.

---

* Бу шигырьгә Гөлчәһрә Байкина көй чыгарган.

Йокла, балам, йокла,
Йом тизрәк күзең,
Бик зур эштә үтте
Синең көндезең.

Йоклый аюларың, йоклый атларың,
Уенчыкларның да йоклар чаклары.
Мич башында песи йоклый берүзе
Син дә йокла, балам, тизрәк йом күзең.
Йокла, балам, йокла,
Йом тизрәк күзең,
Бик зур эштә үтте
Синең көндезең.

Бүгенгедәй матур айлы төннәрдә
Син йөрерсең очып зәңгәр күкләрдә,
Айлы төндә айга юллар салырсың,
Әтиең белән мине искә алырсың.
Йокла, балам, йокла,
Йом тизрәк күзең,
Бик зур эштә үтте
Синең көндезең.





ЭНЕСЕНӘ УЛ АПА *

Мөнир Мазунов шигыре

Җырлый-җырлый кыз бала
Энекәшен йоклата,
Биштә генә булса да,
Энесенә ул апа.

---

* Бу шигырьгә Мансур Мозаффаров көй язган.



Әлли-бәлли бәй итә,
Энем йокыга китә.
Әнкәй, мәми пешереп,
Әткәйне эштән көтә.

Кошлар кунган тирәккә,
Аларны җил тибрәтә.
Тышта җилләр искәндә,
Бәби йоклый мендәрдә.

Әлли-бәлли бәй итә,
Энем йокыга китә.
Йоклатканга энемне,
Әнкәй мине пәп итә.

Йоклый бала, төш күрә,
Көлә, күккә сикерә,
Имеш, аны әтисе
Үсти-үсти иттерә.

Әлли-бәлли бәй итә,
Энем йокыга китә.
Энем йокыга киткәч,
Әни бераз ял итә.



ЙОКЛА, ЭНЕМ *

Разил Вәлиев шигыре

Йокла инде, энем, йокла инде —
Син йокласын диеп, кояш сүнде.
Йокла, энем, йокла инде —
Озын юллар үтеп, йокы килде.

* Бу шигырьгә Рәшит Абдуллин көй язган.

Йокла, энем, йокла, күзләрең йом —
Йокы бит ул — шундый кызык уен.
Йолдыз керер төшләреңә,
Күзләрең йом, тик ят, дәшмә генә.





БИШЕК ҖЫРЫ *

Айдар Хәлим шигыре

Күктә якты ай йөзә,
Җирдә колын ил гизә.
Арыса да колынкай,
Күңелендә уенкай.

---

* Бу шигырьгә Зөлфия Хәлилова көй язган.

Ай сорый колынкайдан:
— Килеп чыктың син кайдан?
Аякларың сигез,— ди,—
Башыңда бар мөгез,— ди.

К у ш ы м т а :

Йокла, балам, йомшагым,
Бәбечем, колынчагым,
Йокла, иртән эшең күп,
Әлли-бәлли, бәү-бәү-бәү...

Колын саный аягын:
— Аягым дүрт, абыем!
Колын чайкый башкаен:
— Мөгезсез мин, айкаем!

Колаклар бит ул шулай
Мөгез сыман тырпайган.
Шәүләм миңа бәйләнә —
Мин икәүгә әйләнәм.

К у ш ы м т а.

Әйтә колын:
— Карап тор!
Мин ничәүмен, санап тор!

Ята колын ук сыман,
Колаклары чук сыман.
Җиргә сеңә колынкай —



Җирдә шундый җылыкай!
Йомыладыр күзләре,
Оеп бара үзләре...

Кушымта.

Бәү-бәү итә урманнар,
Таулар, кошлар, яланнар.
Яшел хәтфә болында
Төшләр күрә колын да.

Бөтен дөнья бәү итә,
Ай бишекне тирбәтә.
Алтын нурда елмая,
Зәңгәр күктән моң ява...

Кушымта.





БИШЕК ҖЫРЫ *

Резеда Вәлиева шигыре

Кояш ятты бишегенә,
Күзләрен йомды.
Кошлар да сайрамый инде,
Чишмәләр тынды.
Яфраклар да серләшмиләр,
Йоклады каен.
... Без дә йоклыйк,
Бәү-бәү итик,
Улым, улкаем...

* Бу шигырьгә Ренат Салихов көй язган.

Песиең дә арыды әнә,
Боегып калды.
Башын салып тәпиенә,
Йокыга талды.
Аюыңа борынын төртеп
Йоклый аткаең...
Без дә йоклыйк,
Бәү-бәү итик,
Улым, улкаем...

Зәңгәр болытлар артыннан
Ай карый көлеп.
Малайларым нишли анда,
Йоклыймы, диеп.

Әкрен басып, йокы бабай
Йөри өй саен...
Әйдә йоклыйк,
Бәү-бәү итик,
Улым, улкаем...







БЕРДӘНБЕРЕМ СИН МИНЕМ *

Фирая Зыятдинова шигыре

Алтыным ла син, диеп,
Ялкыным ла син, диеп
Үстерәм бәбкәемне
Иркәләп, сөеп.
Улыкаем син минем,
Юлыма нур сибүче
Бәхетем минем.
Бәлли-бәү, бәлли-бәү.

---

* Бу шигырьгә Луиза Батыркаева көй язган.



Син минем ышанычым,
Бердәнберем дигәнем;
Син — бөркетем, лачыным,
Илгә бүләгем.
Матур булып үсәрсең,
Батыр булып үсәрсең,
Ак өметем син минем,
Бәхетем минем.
Бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Бәлли-бәү, бәлли-бәү.





СИН МИНЕМ НӘНИЕМ *

Эльмира Шәрифуллина шигыре

Син минем нәнием,
Табигать җимеше.
Син минем җирдәге
Йөрәгем тибеше.

---

* Бу шигырьгә Риф Гатауллин көй язган.

Синдә ул кояшның
Яктысы, нурлары,
Син булсаң, ямьләнә,
Яшәрә Җир шары.

Яңгырның шифасы,
Җылысы син, балам,
Җиремә гомерлек
Җыр булып кил, балам.





Күлләрнең середер —
Күзләрең карасы.
Күзеңә төбәлгән
Туган ил карашы.

Син минем нәнием,
Табигать җимеше.
Син минем җирдәге
Йөрәгем тибеше.





Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга

КОЛЫБЕЛЬНЫЕ ПЕСНИ

(на татарском языке)

Редакторы *Б. Р. Рәхимова*
Бизәлеш редакторы *Ф. Ш. Хәсьянова*
Техник редакторы *Ф. Р. Сәлахова*
Корректоры *Р. Р. Мөбарәкшина*



ИБ № 143

Форматы 70×90¹/₁₆. Офсет кәгазе № 1. Гарнитурасы «Литературная». Офсет басма. Шартлы басма табагы 3,51. Шартлы буяу-оттиск 14,04. Нәшер-хисап табагы 3,12. Тиражы 100 000 экз. Заказ К-11. С 18. «Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур.,19. Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгының Камил Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе. 420111. Казан, Бауман ур., 19.